**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«15» март 2022 ел Иштирәк авылы № 4

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әүзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында»

«Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үз идарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үз идарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслауга гомуми таләпләрнең 10 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын расларга.
2. Әлеге карар 2022 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә гамәлдә була.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районы сайтында (tukay.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Башкарма комитет Җитәкчесе Г.С. Гарифуллина

Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның «15» мартындагы 4 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибе һәм сроклары

1. Әлеге тәртип «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслауга гомуми таләпләрнең 10 пункты нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү механизмын һәм срокларын билгели (алга таба - исемлек, баш администратор).

Баш администраторларның составы һәм (яки) функцияләре үзгәргән, шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге бюджеты керемнәре классификациясе кодларын билгеләү һәм бирү принциплары үзгәргән, исемлеккә, шулай ук баш администраторларга беркетелгәнТатарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге бюджеты керемнәрен классификацияләү кодлары составына үзгәрешләр кертелгән очракта, үзгәрешләрТатарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 3 номерлы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» карарына үзгәрешләр кертмичә кертелә.

Исемлеккә үзгәрешләр федераль һәм төбәк законнарына баш администраторларга беркетелгән бюджеты керемнәрен классификацияләү кодлары составын үзгәртү өлешендә кертелә.